Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге Советы

КАРАР

«23» октября 2024 ел Димтамак ав. №20

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-Фз санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-Фз санлы Федераль закон, 2013 елның 23 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы»ның 50-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Советының 2023 елның 1 мартындагы 2 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 9.3 нче пунктының 5 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. белем һәм квалификация турында документ;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Димтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Ж.Ә.Хөснетдинов